
# Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 144 нче номерлы урта мәктәп»



## Җәләлиева Ләйсән Равил кызы



**Рәдиф Кәшфулла улы Гатауллин** 1941 елның 30 мартында Башкортстан АССРының Кушнаренко районы Марс авылында игенче гаиләсендә туа. Ул ирекле шигырь төрләренә еш мөрәҗәгать итеп, үзеннән форма һәм ритм яңалыклары кертеп, татар әдәбиятын заманча яңгырашлы шигырь үрнәкләре белән баеткан талантлы шагыйрьләрнең берсе.

## *Фәнни - эзләнү эшенең темасы:*

## *“Рәдиф Гаташ иҗатында күчерелмә мәгънәле сүзләр һәм фразеологизмнар”*

.

**Хезмәтемнең максаты** - Рәдиф Гаташның иҗатында кулланылган күчерелмә мәгънәле сүзләр һәм фразеологизмнарны өйрәнү.

**Бурычларым** :

- Р.Гаташның шигырьләрендә күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең төрләрен һәм кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләү;
- Р.Гаташның шигырьләрендә фразеологик берәмлекләрне аерып чыгару һәм кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау.

**Тикшерү объекты** булып Р. Гаташның шигырь текстлары торды.
Әлеге фәнни эшне язуда В.Х. Хаков, Х.Р.Курбатов, С.Ш. Поварисов, С.М.Ибраһимов, И.Б. Бәширова хезмәтләренә нигезләндек.

# Фәнни эшнең төзелеше

Кереш

- Төп өлеш

Йомгаклау

- Кулланылган әдәбият

# Эшнең актуальлеге

**Әдәбият образлы фикерләү дөньясы. Шагыйрь, прозаик яки драматург никадәр образлы фикер йөртсә, ул тудырган әдәби әсәр укучы яки тыңлаучы күңеленә шулкадәр ныграк тәэсир итә, камилрәк һәм матуррак тоела.**

# Нәтиҗәләребез:

- **Р.Гаташның шигырьләрендә кулланылган лексикасына тематик яктан зур төрлелек хас. Тере һәм җансыз табигать, кеше, җәмгыять белән бәйле барлык тематик төркемнәр шигырьләрдә теге яки бу күләмдә чагылыш тапкан.**

*Менә шушы безнең өй.*
*Тиргәмәгез мине, сөйгән дуслар,*
*Тиргәмәгез ерак киткәнгә.*
*Сезгә, бәлки, утрау кебек ошый,*
*Диңгез кирәк ләкин җилкәнгә.*
*Дип, кем иде җанны өзгән,*
*нинди моңнар баласы? (“Ике урман арасы”,Б.181)*

- **Рәдиф Гаташ шигырьләренең лексикасы фигыльләрнең лексик-семантик төркемнәренең күплеге белән характерлана.**

**1) хәрәкәт фигыльләре:**

***Бардыр ул мәхәббәт өчен***
***Сүздә утларга кергән,***
***һәм бар – чын сөюдән, сүзсез! –***
***Үлемнең үзен җиңгән!***
***(“Алтынчы тон, Б. 25)***

## 2) эшчәнлекне белдерүче фигыльләр

*Гөл елыймы, әтием? – дисең. –*
*Чынмы?!*
*Нәрсә әйтим сиңа...*
*Гөл елый шул, улым, бик нык елый,*
*Өзмә аны, тимә. ( “Гөлләр елый улым”, Б.73)*

## 3) хәл-торыш фигыльләре:

***Сагынган дип аңла, аны***
***Күрешергә сузган кулдай***
***Сак кына алдым, дисәм,***
***Сагынганда хисләр дә бит***
***Яктырак, сафрак кебек…***
***(“Җәй бәхете бәйләменнән”, Б.234)***

**4) мөнәсәбәт фигыльләре:**

***Мисал итеп халкыбыз сүз сәнгатен,***
***Мактарсың, беләм, шагыйрьләр өммәтен!***
***("Куркытмыймы алда имтиханың, Яр?", Б.325)***

**5) тавыш фигыльләре:**

***Ташый елга, шарламалар, гөрләвекләр…***
***Су тавышы төшләрендә гүләр, күкрәр.***
***("Ничек шулай үзгәрде?", Б.206)***

- **Р.Гаташ шигырьләрендә сыйфатның лексик-тематик төркемнәре:**

***Әй беренче кат күрү!***
***Сине очраткан бер төн***
***Ачты каршымда бер кызның***
***Тылсымлы сихри битен.***
***("Җиде төн", Б.21)***

***Зур рәхмәт тапкан анама! –***
***Мин талант, көчле талант…***
***Әй, горур гүзәл, син мине***
***Ярат тик, мәңге ярат!***
***("Җиде төн, Б.23)***

***Сары песи сарган яшел таллар ботагында Тирбәлергәме әллә бер тагын да?("Ничек шулай үзгәрде?", Б. 206)***

***Зифа бөдрә тирәкләр***
***Безнең өчен үскәннәр,***
***Тәмле кура җиләкләр***
***Безнең өчен пешкәннәр.***
***("Бер югалту", Б.179)***

# Р.Гаташ иҗатында синонимнар

**Синоним исемнәр:**

- *көч, гайрәт, куәт, дәрман;*
- *дус, ахирәт, иптәш, сердәш;*
- *болын, дала, чүл, елан;*
- *өй, йорт, Җир;*
- *яу (сугыш), сугыш, дау, көрәш;*
- *бәхетсезлек, кайгы, бәла;*
- *хан, солтан. Падишаһ;*
- *боерык, әмер;*
- *тиң, иш һ.б.*

**Синоним сыйфатлар:**

- *чибәр, матур, сөйкемле;*
- *гайрәтле, йөрәкле;*
- *татлы, тәмле;*
- *дивана, ахмак, башсыз;*
- *гамьсез, юньсез һ.б.*

**Синоним фигыльләр:**

- *качу, котылу;*
- *кире кагу, каршы килү;*
- *адашу, югалу;*
- *кайгыру, борчылу;*
- *якын күрү, кадерләү*
- *елмаю, көлү һ.б.*

-  **Абсолют синонимнар:** ***былбыл, сандугач; исем, ат; угыл, сагыну, юксыну.***

-  **Эмоциональ-экспрессив синонимнар**

***Һәрчак алда,***
***Киләчәккә юллар сызып йөри.***
***Малайларны да бит – тарта батырлыклар,***
***Ерак юллар, адаштырган утлар.***

**Чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар, сынландыру кебек сурәтләү чаралары:**

*Җиргә тик гашыйклар кебек*
*Сокланып карау хисе*
*Яшиме миндә? Исәнме*
*Өметнең сихри көче? ("Җавап бир, тибигать", Б. 219)*

*И былбыл фәне, син чорлар*
*Якынлыгы белән көчле!*
*Илаһи да, гади дә син,*
*Һава, су икмәк төсле...*
*("Былбылга эндәшү", Б.266)*

**1) гомумтел метафоралар:**

***... Якын Марс авылым!***

***Туган йортым, туган җирем!***

***( “Ерак Марс авылы!”, Б. 160)***

**2) гомумпоэтик метафоралар:**

***Шашындырган тиле көчкә...***

***Бер исем тап син шуларга!***

***(“Ирләр булыйк”, б. 90)***

**3) автор метафорасы:**

***...Чәчләрең сөртә яшемне,***

***Миндә дә дымлы моң бар.***

***Миндә дә кыен сораулар... (“”Чәчләреңә төрдең мине”, Б. 328)***

# Сынландырулар

*Сагынып сине, лаләләр күз ача,*
*Казанда – нәркисләр хәлеңне сораша.*
*(“Кайт тагын”, Б. 305)*

*Туктатырга уйлап Сине, Вакытны,*
*Бар Галәмне – кулыннан кысып тотсам...*
*(“Коткарырга теләп сине Ялгыштан” , Б. 372)*

# Фразеологик әйтелмәләр:

**исем + исем моделе:**

***Гүзәллек, син – байлык колымы һаман? –***
***Сине йолу әмәлен табыйм каян?***
***(“Күпме хат-китап бар гүзәл җенескә”, Б. 329)***

**исем + фигыль моделе:**

***Алда булсын яуларда,***
***Дан казансын дауларда.***

**сыйфат+ исем + фигыль моделе:**
***Мөдәрис, Зөлфәт! Белмисез хәлем сез:***
***Үзе матур, сүзе суык, рәхимсез***
***Яшь кыз әсир итте... янам да язам,***
***Тагын нишли алам? Бәлки әйтерсез?***
***(“Шагыйрь дусларыма”, Б. 456)***

**исем + исем + исем + фигыль моделе:**
***Күңелебезгә шатлык утын якты***
***Сиңа күптән мәгълүм гыйшкым төсле ул...***
***(“Югалтулар күп бу җирдә”, Б. 463)***

# Игътибарыгыз өчен, рәхмәт!